РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423586, г. Нижнекамск, пр. Строителей, 12
тел./факс (8555) 41-70-00

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

423586, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
тел./факс (8555) 41-70-00

РЕШЕНИЕ КАРАР

№ 40 2022 елның 26 августы

# Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «Афанас авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планын яңа редакциядә раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2022 елның 8 апрелендәге 01-09-5513 номерлы уңай бәяләмәсен исәпкә алып, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «Афанас авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планын яңа кушымта итеп бирелгән редакциядә расларга.
2. Түбән Кама муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Афанас авыл җирлеге генераль планын раслау турында» 2017 елның 24 гыйнварындагы 4 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районы Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
4. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш һәм архитектура идарәсенә расланган документны Россия Федерациясе территориаль планлаштыру федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны төзелеш, җир төзелеше, торак-коммуналь хуҗалык һәм транспорт буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль районы
Башлыгы вазыйфаларын башкаручы,
Башлык урынбасары

ПРЕДСТАВИТЕЛЬНЫЙ ОРГАН
ВӘКИЛЛЕКЛЕ ОРГАН

А.В.Умников